ТУГАН АВЫЛЫМ

# Йөрәк моңым Корбанай



Кеше дигән нәрсә гаҗәеп җан иясе. Ул туганнан бирле каядыр ашыга, нәрсәгә омтыла, бүгенге яшәүе аңа һәрчак вакытлыча гына, ә чын тормыш кайдадыр алда, киләчәктә кебек тоела. Шулай итеп сизелми дә кайгы — гамсез балачагы, борчылу мәшәкатьле уку еллары, баш — аяктан чумып эшкә җигелеп тормыш куган чаклар утеп китә. Әйләнеп карасаң шаулап — гөрләп торган гомер артта калган — картлык җиткән. Шулчак кеше үзе үзенә бәя бирә, нәтиҗә ясый, уйлый: кем мин, нәрсә мин? Ничәмә дистәләгән гомер йомгагыңа күз салсаң ул күп сериялы кинофильмның кадрлары кебек ап — ачык ялтырап ята һәм, әлбәттә, балачакка, авылыңа әйләнеп кайта.

Минәм туган авылым татар мөселман кешесенә бик ягымлы, матур булып ишетелә: аның исеме Корбанай. Ә нигә алай икәне көн кебек ярылып ята. Бу авылга безнең әти — бабаларыбыз ХУ11 гасырдан бирле Зур Кинәле елгасы буенда урнашкан Иске Солтангол авылыннан мөселман календаре хиҗрә буенча 1920 елларның корбан аенда буленеп чыканнар һәм нигезен салганнар. Ә тарихы аның гап-гади. Әле патша хөкемәте чорындагы законнар заманы буенча авылда яшәгән ир-ат затларына гына җир бирелгән икән, ә татар халкы ул вакытта тиз үрчегәнгә Иске Солтангол халкына җир җитешмәгән. Шушы шартларны искә алып әле яңа гына барлыкка килгән Совет хакимияте резерв җирләрдән Иске Солтангол халкына 500-600 гектар җир бүлеп биргән. Билгеле ул җирләргә беренче булып яңа гына гаилә корган, куллары җир эшкәртерчә мал карарга күнеккән яшь йөрәкле егетләр килгән. Минем гаилә альбомында шуларның берничәсенең бик сирәк калган, бәлки берданбер экземпляр, картайгач күмәк төшкән фотосүрәтләре бар. Шуны тәкъдим итәм. Бәлки минәм авылдашларыма алар кадерледер, чөнки бу бабайларның барысының да хәзерге көндә Корбанайда һәм Әсәкәйдә балалары яки оныклары яши.Сулдан уңга: Дәүләтхуҗин Шаяхмәт Кунакбай улы, Сөләйманов Морзахан Сөләйман улы, Бәдриев Сафуан, Әхмәтҗанов Хәйбулла, Зиянгулов Сафа. Гадәттә авылга урын сайлаганда борынгы халык елга буен, тау итәген, урман ышыгын кулай күргән. А Корбанай бу табигать байлыкларының барысыннан да мәхрүм, чөнки нигез салучыларның сайланырга вариантлары булмаган: бүлеп бирелгән кола яланның уйсуран җиренә кечкенә буа буып шунда авыл корганнар. Кубрәк йортлар саман стеналы, җир идәнле, ясы түбәле булган. Авыл кешесенең бөтен байлыгы җир булганлыктан һәр гаиләнең төп кәсебе иген игү, мал асрау булган. Шуңа күрә гаиләдә 2-3 ир заты, 3-4 аты булса ул иң байлардан саналган, бу хәлләрне мин әтиемнең һәм олырак абыйларым сөйләвеннән беләм. Ә үзем ачык белә башлаган чакларым 5-6 яшьтә, сугыш елларына туры килә.

Бүгенге көндә минем 6 яшьлек Әлисә исемле оныкчыгым бар. Безнең балачакларның аермасы күк белән җир, оҗмах белән тәмуг кебек аерыла. Аллага шөкер әтисе-әнисе эштә, абыйсы мәктәптә чакта Әлисә балалар бакчасында ашап- эчеп, ял итеп, уйнап, җырлап-биеп кайта да өйдә тагын телевизорга, компьютерга ябыша.

Ә минем очракта бөтен исәнсау олы яшьтәге кешеләр, шул исәптән минем дә өч абыем: Фәтих, Мөхәммәт, Каһарман сугышта әнием һәм минем 6 яшькә олырак абыем Харис, 8 яшькә олы абыем Җәмиль, 10 яшь олы апам Мөслимә, Җиңгиебез Асия көне-төне колхоз әшендә булганга без миннән 2 яшькә олырак Мөслимә апам, 2 яшь кече Фатых абыемның улы Барый белән өстән бикләнгән көенә ачлы-туклы, ярым ялангач, салкын караңгы өйдә утыра идек. Хәзерге сүзлектән чыгып мин шуны әйтәсем килә: безнең әниләребез, олы апаларыбыз һәмма хатын-кызларыбыз тылдагы авыр хезмәтне үз иңнәрендә кутәреп кенә калмаганнар, алар хезмәт сөюдән, иленә бирелгән тәртипле балалар үстергәннәр, ирләренә тугрылыклы булып калганнар, фронттагы ирләрен, уларын үзләренең сүзләре белән җинүгә рухландырганнар. Нинди генә авыр еллар булса да, хуҗалыгыбызда сыер, сарык-кәҗә, тавык-кош булгангадыр, шул елларда бөтенләй ачка интегеп утырганымны хәтерләмим. Рәхмәт яусын әтиәниемә, апа-абыйларыма.

1946 елның 1-че сентябрендә без Корбанайның 8-әр яшьлек 6 баласы — 4 малай, 2 кыз — тантаналы рәвештә мәктәп парталары артына кереп утырдык. Бу зур вакыйга хөрмәтенә әнием миңа иске чүпрәктән букча тегеп бирде, әтием дәфтәр урынына иске амбар китабы тоттырды. 1-че сыйныф укучыларына ярты ел ручка белән язарга рөхсәт ителми иде. Укытучыбыз Ягудин Габдельхак Равил улы безгә яртышар кәлам таратты (1-не икегә кисеп).Киләчәктә 10-15 елга сузылачак белем чишмәсенә чумганда барлык уку-язу кулланмалары шулар булды. Бу язманы укучыларда "белемегез дә шундый гына булгандыр" диеп фикер туарга мөмкин. Һич тә алай түгел. Киресенчә "ул вакыттагы программаларның төпле, нигезле, системалы икәнлегенә, укытучыга ышану , аны ихтирам итүгә эле хәзер дә сокланып туя алмыйм.

**(дәвамы бар)**

**Әмир СӨЛӘЙМАНОВ.**
**Әсәкәй авылы.**

КНИЖНЫЕ НОВИНКИ

# О Бугуруслане на татарском языке

**Большое событие ожидается в Бугуруслане. Готова к выпуску книга, рассказывающая о городе Бугуруслане, его истории, важнейших событиях. Автор — известный в городе татарский общественный деятель М.Г.Закиров. Марат Галимзянович после окончания Казанского государственного университета всю трудовую жизнь посветил педагогике. Но даже после выхода на пенсию не прекращает общественно-просветительскую работу, является заместителем председателя татарского общественного центра города.**

**Предлагаем вам фрагменты этой книги:**

"Идел — Урал арасында Бөгелмә — Бәләбәй калкулыгы, дистәләр чакрымга җәелеп — сузылып Кинәле елгасына житкәч, тукталып кала. Шушы Кинәле яры янындагы ике тау арасында кечкенә бистә (слободка) барлыкка килә. Бу җирдә күптән үк төрки кабиләләре яшәгән. Ә Турханка елгасының сул ягындагы тауны әле дә халык слобода дип атый.



1901 елда Санкт — Петербургта "Пособие по Нижнему и Среднему Поволжью" дигән китап чыга. Шул китапның 6-нчы томында, 431 битендә болай дип язылган: "Богырыслан җирендә, күрәсең, элек тә халык урнашкан булган. Шихан тауының битендә, Тарханка елгасы буенда җирдән өйгән ныгытмаларның калдыклары сакланган. Күптән шәһәрдә яшәүчеләр аның калган эзләрен истә тоталар. Аларның сөйләүләре буенча, бирердә я татар шәһәрчеге, я русларның каравыл пункты булган диләр". 20-нче гасырның утызынчы елларында Богырысланда беренче музей төзүче, крайны сөюче һәм археолог Аниховский Александр Леонтьевич казу эшләре оештыргач, шунда бистәне урап алган җир оемнәре таба һәм монда кайчандыр халык яшәгәнен раслый. Бу җирләрдә төрки халкы яшәгәнен шәһәрләр, авыллар исемнәре дә раслый Мәсәлән, тирә яктагы авылларны алсак, алар әле дә татар исемнәрен йөртәләр: Йолдыз, Алга, Чишмә — баш, Әсәкәй, Мәтеби, Солтангыл, Гали авылы, Балыклы, Камышлы һ.б. Бозаулык дигән шәһәр дә ерак түгел.

Бу җирләрдә бик куе урманнар үскән, кара туфраклы җир ашлыкларны үндырган, балыкка бай сулар, чиста, татлы сулы чишмәләр булгач, бирердә күчмә халык башкортлар да вакытлыча яшәгәннәр. Аларның батырларын "арыслан" дип кушамат биргәннәр. Шуңа күрә бер уйдырмада Богырыслан исеменә "арслан бакчасы" дигән аңлатма бирелә.

Икенче уйдырма шәһәр исемен бу җирдә беренче булып Руслан дигән кеше торган дип аңлата. Ырымбур крайны өйрәнүче Попов Сергей Александрович шәһәрнең топонимикасын Богырыслан елгасының исеменнән алынган ди, чөнки елга элек зур сулы, арыслан кебек көчле агымлы булганын раслый. Ул елга тирәсендә Сергей Тимофеевич Аксаков яшәгәндә, ул да Богырыслан елгасының зур, балыкка бай сулы дип яза. Ә "буга" дигән сүз Владимир Иванович Дальның аңлатма сүзлегендә "елгаларның язгы ташу вакытында су баскан әрәмә тугайлары" дип төшендерә. "Буг", "Бог" дигән сүз нигезләре күп исемнәрдә очрый, мәсәлән: Алабуга, Бикбуга, Карбуга, Бөгелмә, Богырыслан һ.б.

18-нче гасырның утызынчы елларда Ырымбур җирләрен тикшереп чыгу өчен экспедиция оештырыла. 1735елда аның башлыгы Кириллов Иван Кириллович хәзерге Орск урынында Ырымбур ныгытмасы төзи, ә аны алыштырган Татищев Василий Никитич 1739елда ныгытманы яңа урынга Кызыл тау янына күчермәкче була, ләкин аны булдыра алмый. Ахрыда Неплюев Иван Иванович 1743 елны аны өченче урында, Җаек елгасы ярында төзи. Ырымбур инде үзенең урынып таба, ә бер елдан соң Ырымбур губерниясе барлыкка килә. Губерниядә кырыкка якын ныгытмалар, тораклар, редутлар төзелә.

Рычков Петр Иванович Ырымбур далаларының табигатен һәм казылма байлыкларын фәнни тикшерә. Аны Ырымбур Колумбы, Ырымбур Ломоносовы дигән кушаматлары халыкның истәлегендә кала.

Бирегә, табигатькә бай, уңдыручан җирләргә Русия губернияләреннән халык агыла. Байлардан качып йөргән крестьяннар, казаклар, төрле кабилә, төрле милләт кешеләре: руслар, украиннар, мордвалар, чуашлар, казаклар килеп урнашалар.

Бу турыда Сенатның бер документы бар. 1744 елның 6 мартында чыккан документында Олы һәм Кече Кинәле елгалары исеме телгә алына. "Иң биек хакимлек итеп Кинәле буена черкесларга урнашырга рөхсәт бирелә" дигән.

1748 елның азагында Ырымбур губерния канцеляриясе указ чыгара, аның буенча Богырыслан бистәсенә туган — кабиләләрен белештермәгән кучем халыкка урнаштырырга рөхсәт бирелә. Бу указ әлегә хәтле архивта сакланмаса да, бөтен язма чыганаклар шушы указга сылтау итәләр.

Шушы 1748елны Богырысланның туган елы дип саный башлыйлар.

18-нче гасырдагы Богырыслан бистәсенең күренеше нинди булган соң?